БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» 12 2024 ел № 317

Аз керемле буларак статусларын һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы һәм аның составына керүче авыл җирлекләренең муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары алуга хокукларын кабат раслау максатларында исәпкә алынган гражданнарның мөлкәте бәясен һәм керемнәрен яңадан бәяләүне үткәрү ешлыгын һәм вакытын билгеләү турында

Татарстан Республикасының 2007 елның 13 июлендәге «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирелү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 31-ТРЗ номерлы Законының 21 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Ел саен 1 гыйнвардан 1 майга кадәр аз керемле буларак статусларын һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы һәм аның составына керүче авыл җирлекләренең муниципаль торак фондыннан һәм социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары алуга хокукларын кабат раслау максатларында исәпкә алынган гражданнарның мөлкәте бәясен һәм керемнәрен яңадан бәяләүне үткәрергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (baltasi.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов